# Чишмә башы

## Урта Курса төп гомуми белем мәктәбе

**Декабрь, 2024 нче ел**

**Бу санда**

- 3 нче декабрь – Билгесез солдат көне
- 18 декабрь- Кар көне
- Укучыларыбыз иҗаты




***Билгесез солдат көне – Россиядә 2014нче елдан башлап һәр елны 3 декабьдә билгеләп үтелә. Бу истәлекле көннең мәгънәсе – сугыш хәрәкәтләрендә һәлак булган, ләкин шул ук вакытта исемнәре билгесез калган сугышчыларының үлемсез батырлыкларын хәтерләүне мәңгеләштерү. 3нче декабрь көне очраклы гына сайланмады. Нәкъ менә 1966 елның 3 нче декабрь көнендә Мәскәү астында немец-фашист гаскәрләрен тар-мар итүнең 25 еллыгы уңаеннан, Ленинград шоссесының 41нче километрындагы һәлак булган совет сугышчыларының туганнар каберлегеннән билгесез солдат җәсәде Мәскәү Кремле стенасы буендагы Александров бакчасына кайтарып җирләнде.***

***Билгесез солдат каберенә куелган плитәгә «Исемең синең билгесез. Батырлыгың мәңгелек» дигән сүзләр язылган.***

Билгесез солдат көне – ул Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарны искә алу һәм хөрмәтләү генә түгел, ул сугышларда яки хәрби конфликтларда һәлак булганнарны, хәбәрсез югалганнарны барысын да берләштерү көне дә. Ул Ватанны саклаган һәм фронтларда һәлак булган һәр солдатны хәтерләү һәм мәрхәмәтлелек күрсәтү көне дә.



# Укучыларыбыз иҗаты

## ТИЗДӘН ЯҢА ЕЛ!

Яңа ел.Нинди матур сүз!Бу бәйрәмне мин бик яратам.Ул утыз беренче декабрьдә була.Яңа ел кичендә бөтен теләкләр чыңга аша.
Иртүк уянып чыршы астына карасаң,анда без теләгән матур бүләкләр ятачак.Ул-безнең өчен бик зур бәхет.
Яңа елда барыбыз да өстәл әзерлибез,кунаклар чакырабыз.Ә яңа ел җитәр алдыннан, безнең Россия президентының сүз әйткәнен, теләкләр теләгәнен телевизордан күрсәтәләр.
Яңа еллар безгә бәхет һәм уңышлар китерсен!

*Насыйбуллина Раяна, 6нчы сыйныф укучысы*



## КЫШКЫ КӨН.

Карлары белән суык кыш килде.Кояш та әз генә күренеп тора, ә аннары офыкка кереп югала.
Кыш көне көннәр бик матур һәм якты.Агачлар,куаклар ап-ак бүрекләрен,туннарын киеп куялар.Салкын көннәрдә агачларда, чыпчыклар чыркылдавы гына ишетелә.Кыш айлары үзенең суыклары һәм бураннары белән истә кала.Мин үзем кышны ап-ак карлары булуы,саф һавасы өчен яратам.

*Ахунҗанова Зилә, 6нчы сыйныф укучысы*

# Укучыларыбыз иҗаты

## КЫШКЫ УРМАН.

Карлары,бураннары белән салкын кыш килде.Кышкы табигать бик матур була.Аеруча кыш көне урман бик матур һәм якты.Куаклар ап-ак бүрек кияләр.Урман хуҗасы аю,тәмле төшләр күрә-күрә рәхәтләнеп йоклый.

Менә кинәт җил чыкты.Җәяүле буран башланды.Урман карга күмелде. Табигатьнең гүзәллеген күрә һәм тоя белергә кирәк.

*Хуҗиәхмәтов Нияз,6нчы сыйныф укучысы*



## КЫШНЫҢ ЭНҖЕ-МӘРҖӘННӘРЕ.

Кышкы урман куркыныч та, матур да.Төнлә әллә нинди шом бар анда.Урман ягыннан көчле җил дә иссә, тагын да куркынычрак булып китә.Әллә нинди күз күрмәгән җанварлар, колак ишетмәгән тавышлар чыгара сыман.

Ә кояш чыккач,яктыргач безнең каршыда искиткеч матур пейзаж ачыла.Чыршы-наратлар ак мамык шәл ябына,каеннар ялтыравыклы күлмәкләр кия.Урман ягыннан искән җил дә саф һавалар,хуш исләр алып килә.Берән-сәрән ишетелгән кош тавышлары да күңелгә рәхәтлек бирә.Урман буена барасы,карлы агачларны кочасы килә.

*Гарифуллина Мәрьям,6нчы сыйныф укучысы*




***18 ДЕКАБРЬДӘ КЫЗЫКЛЫ, ГАҖӘЕП ҺӘМ ТЫЛСЫМЛЫ КӨН — КАР БӨРТЕГЕ КӨНЕ БИЛГЕЛӘП ҮТЕЛӘ! КАР БӨРТЕКЛӘРЕНЕҢ ФОРМАЛАРЫ ҺӘМ РӘСЕМНӘРЕ ГАҖӘЕП КҮПТӨРЛЕ БУЛУЫН БЕЛӘСЕЗМЕ? АЛАРНЫҢ ҺӘРКАЙСЫ БИЕК БОЛЫТЛАРДА БАРЛЫККА КИЛӘ ҺӘМ, ТӨРЛЕ ТЕМПЕРАТУРАЛАР ҺӘМ ДЫМЛЫЛЫК АША ҮТЕП, ҮЗЕНЕҢ КАБАТЛАНМАС СТРУКТУРАСЫН АЛА. НӘКЪ МЕНӘ ШУҢА КҮРӘ БЕР КАР БӨРТЕГЕ ДӘ ИКЕНЧЕСЕНӘ ОХШАМАГАН-БУ ТАБИГАТЬНЕҢ ЧЫН МОГҖИЗАСЫ.***

### *Кышкы табышмаклар*

***Мамык юрган, кат-кат сырган,***
***Үзе суп-суык. (Кар)***
*********
***Каз мамыгын кагына,***
***Кагына да тузына. (Буран)***
*********
***Тәңкә карлар сибелгән,***
***Җир ап-акка күмелгән.***
***Чыршы, каен, имән***
***Кардан чикмән кигән.***
***Бу кайчак? (Кыш)***
*********
***Ак мамык кебек,***
***Ялтырый алмаз кебек. (Кар)***
*********
***Оча – юк канатлары,***
***Чаба – юк аяклары,***
***Тышта булса өелә,***
***Өйгә керсә, җәелә. (Кар)***



### *Кышкы табышмаклар*

***Шома табанлы чана,***
***Атсыз да алга чаба -***
***Җитез булса аяклар,***
***Кулда булса таяклар. (Чаңгы)***
*********
***Ике агай тездән,***
***Калышмыйлар бездән. (Итек)***
*********
***Колаклы ябалак суыктан саклый. (Бүрек)***
*********
***Бер ягы – кыр, бер ягы урман. (Тун)***
*********
***Биш агайга бер күлмәк. (Бияләй)***
*********
***Бер агачта биш тармак,***
***Тармагы саен бармак. (Пирчәткә)***
*********
***Йолдыз, йолдыз вак кына,***
***Яфраклары ак кына.***
***Өс киеменә куна,***
***Тәнгә тисә, су була (Кар бөртеге)***

